КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 29 май г.Казань № б-1173

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү эшчәнлеген камилләштерү максатларында:

1. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү эшчәнлеген камилләштерү буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү эшчәнлеген камилләштерү буенча ведомствоара комиссия турында һәм аның составын раслап расларга.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 май, б-1173 нче
боерыгы белән расланды

# Каты коммуналь калдыклар белән эш итү эшчәнлеген камилләштерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Каты коммуналь калдыклар белән эш итү эшчәнлеген камилләштерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) каты коммуналь калдыклар белән эш итү эшчәнлеген камилләштерү максатларында төзелә.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## II. Ведомствоара комиссиянең бурычлары һәм функцияләре

2.1. Ведомствоара комиссиянең төп бурычы – каты коммуналь калдыклар белән эш итү эшчәнлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2.2. Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурыч нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторлары эшчәнлеге нәтиҗәләрен карау;

каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәрне гомумиләштерү һәм анализлау.

## III. Ведомствоара комиссия составы

3.1. Ведомствоара комиссия ведомствоара комиссия җитәкчесе, ведомствоара комиссия җитәкчесе урынбасарлары, секретаре һәм ведомствоара комиссия әгъзалары составында төзелә.

3.2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары (килешү буенча) һәм оешмалар (килешү буенча) вәкилләре керә.

3.3. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне ведомствоара комиссия җитәкчесе башкара, ул:

ведомствоара комиссия утырышын үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгели;

ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен раслый;

ведомствоара комиссия утырышларын алып бара;

ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләренә һәм карарларына имза куя;

эшче төркем тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

ведомствоара комиссия җитәкчесе урынбасарлары, ведомствоара комиссия секретаре һәм аның әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә.

3.4. Ведомствоара комиссия әгъзалары:

ведомствоара комиссия утырышларында шәхсән үзләре катнаша;

ведомствоара комиссия утырышында катнашу мөмкинлеге булмаганда, бу турыда ведомствоара комиссия утырышы башланганга кадәр ведомствоара комиссия җитәкчесенә хәбәр итә;

ведомствоара комиссия җитәкчесенә ведомствоара комиссия утырышларында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр бирә.

3.5. Ведомствоара комиссия секретаре:

ведомствоара комиссия әгъзаларының ведомствоара комиссия утырышында каралырга тиешле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрен гомумиләштерә, ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен төзи һәм аны ведомствоара комиссия җитәкчесенә җибәрә;

ведомствоара комиссия утырышларына материаллар, шулай ук карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

барлык кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән ведомствоара комиссия әгъзаларын һәм чакырылган затларны тәэмин итә;

ведомствоара комиссия утырышы беркетмәсен алып бара.

## IV. Ведомствоара комиссиянең эш тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге ведомствоара комиссия утырышлары рәвешендә гамәлгә ашырыла. Ведомствоара комиссия утырышы, әгәр анда ведомствоара комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Ведомствоара комиссия утырышлары ведомствоара комиссия тарафыннан карап тикшерелергә тиешле мәсьәләләр барлыкка килгәндә кирәк булуга карап үткәрелә. Ведомствоара комиссия утырышлары ведомствоара комиссия җитәкчесе тарафыннан, ә ул булмаганда яки аның йөкләмәсе буенча ведомствоара комиссия җитәкчесе урынбасары тарафыннан уздырыла.

4.2. Ведомствоара комиссия карарлары ведомствоара комиссия составына керүче, утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә, беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм ведомствоара комиссия җитәкчесе яки ведомствоара комиссия җитәкчесе урынбасары тарафыннан имзалана. Тавышлар тигез булганда, ведомствоара комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Ведомствоара комиссия утырышының имзаланган беркетмәсе һәм аның кушымталары күчермәләре, алга таба эшләү өчен, өч эш көне эчендә ведомствоара комиссия әгъзаларына электрон рәвештә җибәрелә.

________________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 29 май, б-1173 нче
боерыгы белән расланды

Каты коммуналь калдыклар белән
эш итү эшчәнлеген камилләштерү буенча ведомствоара комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, ведомствоара комиссия җитәкчесе |
| Фролов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары, ведомствоара комиссия җитәкчесе урынбасары |
| Шараев Марат Мәгъруф улы | Татарстан Республикасы прокуратурасының федераль законнар үтәлешен күзәтү идарәсе башлыгы, ведомствоара комиссия җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Краснова Диана Викторовна | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының калдыклар белән эш итү бүлеге башлыгы, ведомствоара комиссия секретаре |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Александров Денис Алексеевич | Идел буе төбәкара табигатьне саклау прокуратурасының Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы прокуроры (килешү буенча) |
| Алимов Гадел Равил улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының үзәк территориаль идарәсе башлыгы |
| Манидичева Ольга Владимировна | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары |
| Низамиев Айрат Шәкертҗан улы | Татарстан Республикасының Татарстан табигатьне саклау районара прокуратурасы прокуроры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Петров Дмитрий Владимирович | «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарә итүче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Попова Елена Евгеньевна | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсенә караган дәүләт экология экспертизасы һәм рөхсәт бирү эшчәнлеге төбәкара бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Прокофьева Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Сибгатуллина Энҗе Әхмәт кызы | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең коммуналь гигиенага күзәтчелек бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Фәһимов Евгения Анатольевна | «Гринт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Фәйзетдинова Гөлназ Рәис кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары секретариаты баш киңәшчесе |
| Хәбибуллина Лариса Васильевна | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары |
| Шәвәлиев Рөстәм Хәйдәр улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге баш киңәшчесе |
| Шиһапов Айрат Миннемарсил улы | Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча). |